
# БАЛКЫП ЯШӘ, ТАТАРСТАН!










1920 елның 25 июнендә Казан губернасы башкарма комитеты үз вәкаләтләрен ТАССРның Революцион комитетына тапшыра. Бу көн ТАССРның туган көне булып санала.




ТАССР оешуны бәйрәм итү 1920 елның 25 июнендә Юнысов мәйданында уза





**Декрет Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета Советов.**

**222. Об Автономной Татарской Социалистической Советской Республике.**

Всероссийский Центральный Исполнительный Комитет и Совет Народных Комиссаров постановляют:

I.

1. Образовать Автономную Татарскую Социалистическую Советскую Республику, как часть Российской Социалистической Федеративной Советской Республики, и в состав ее включить:

а) из Казанской губернии: уезды Казанский, Лаишевский, Мамадышский, Свияжский, Чистопольский, Тетюшский и Спасский, за исключением волостей Жидневской и Юркульской, и волости Елабужского уезда — Черкасовская и Солаушская и Краснококшайского уезда — Кулле-Кимынская и Кшкловская;

б) из Уфимской губернии: Мензелинский уезд;

в) из Самарской губернии: волости Бугульминского уезда — Азнакаевская, Александровская, Альмеевская, Альметьевская, Бавлинская, Богоявленская, Варваринская, Верхне-Кармальская, Каратаевская, Кузайкинская, Ивановская, Масягутовская, Микулинская, Мордовско-Афонинская, Мордовско-Ивановская, Мордовско-Кармальская, Нижне-Чершелинская, Ново-Песмипская, Салиховская, Спасская, Спиридоновская, Стерлитамакская, Сумароковская, Тумутуковская, Урсалинская и Чекапская;

г) из Вятской губернии: волости Малмыжского уезда — Кошкинская, Нослинская, Арборовская, Янгулавская, Сардыбашевская, Нижне-Четавская и Шудинская;

д) из Симбирской губернии: волости Симбирского уезда — Сюндюковская, Б. Тархановская и Б. Кильнинская: волости Буинского уезда — Старо-Студенецкая, Эктугановская, Шикирдановская, Ново-Какрлинская, Дрожжановская, Мочалеевская, Бурундуковская, Рунгинская, Хизбаевская, Убеевская и Городищенская.

*Примечание.* Вопрос о включении в состав Татарской Социалистической Советской Республики Белебеевского и Бирского уездов Уфимской губернии оставить открытым впредь до волеизъявления трудящегося населения этих уездов.

II.


2. Аппарат государственной власти Автономной Татарской Социалистической Советской Республики складывается, согласно конституции Р. С. Ф. С. Р., из местных Советов Депутатов, Центрального Исполнительного Комитета и Совета Народных Комиссаров Татарской Социалистической Советской Республики.

3. Для управления делами автономной Татарской Социалистической Советской Республики учреждаются Народные Комиссариаты: 1) Внутренних Дел с Управлением Почт и Телеграфов, 2) Юстиции, 3) Просвещения, 4) Здравоохранения, 5) Социального Обеспечения, 6) Земледелия, 7) Продовольствия, 8) Финансов, 9) Совета Народного Хозяйства с отделами Труда и Путей Сообщения и 10) Рабоче-Крестьянской Инспекции.

*Примечание.* Иностранные дела и внешняя торговля остаются целиком в ведении центральных органов Р. С. Ф. С. Р. Военными делами ведает Татарский Военный Комиссариат, непосредственно подчиненный ближайшему Окружному Военному Комиссару. Борьба с контр-революцией остается в ведении органов Всероссийской Чрезвычайной Комиссии, организованных Всероссийской Чрезвычайной Комиссией по соглашению с Татарским Советом Народных Комиссаров.

1920 елның 27 маенда ТАССР төзелү турындагы Декрет басыла, аңа Халык комиссарлары Советы рәисе В.И.Ленин, Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты рәисе М.И.Калинин һәм БҮБК секретаре А.С.Енукидзе кул куя.

# ТАССР ның беренче җитәкчеләре




1920 -1921 елларда ТАССР Үзәк башкарма комитеты (Тат ЦИК) рәисе Борхан Мансуров



Халык комиссарлары шурасының (Совнарком) беренче рәисе - Сәхибгәрәй Сәетгалиев

1921 -1924 елларда халык комиссарлары шурасы рәисе Кашшаф Мохтәров



# 30 елларда Татарстан илнең индустриаль яктан алга киткән төбәгенә әверелә

1927 -1937 елларда Татарстанда индустриальләштерү колач җәя. Машина төзелеше, нефть химиясе, энергетика, җиңел сәнәгать җитештерү тармаклары барлыкка килә: Казан мех комбинаты, Казан авиакомбинаты (1932), «Пишмаш» заводы (1933), Синтетик каучук заводы (1932-1934), Кинофотокомбинат (1933-1935), ТЭЦ-1, ТЭЦ-2 предприятиеләре сафка бастырыла.



№22 нче заводта (булачак Казан авиация заводы)

# ТАССРда авыл хуҗалыгын күмәкләштерү

1927 елда тоташ күмәкләшү барышында крестьяннар колхозларга керүдән һәм дәүләткә икмәк тапшырудан баш тарталар.1930 елга таза тормыш алып барган 14 меңгә якын хуҗалык юкка чыгарыла. 40 мең кеше республикадан читкә сөрелә, озак срокларга төрмәләргә һәм лагерьларга озатыла.




1934 елның 3 гыйнварында ТАССРны Ленин ордены белән бүләклиләр. Анда мондый сүзләр бар: «Төп авыл хуҗалыгы эшләрен (чәчү, урып-җыю җыю, орлыкка калдыру) үткәрүдә, колхоз һәм совхозларны ныгытуда һәм дәүләт каршындагы бурычларны үтәүдә гаять зур уңышлары өчен».

# Милли үсеш еллары

ТАССР да талантлы фәнни һәм иҗади милли интеллигенция вәкилләре үсә. Татар әдәбиятында Гадел Кутуй, Һади Такташ, Кави Нәҗми, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, профессиональ музыка өлкәсендә – Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши, Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, театр сәнгатендә – Кәрим Тинчурин, Хәлил Әбҗәлилов, Фатыйма Ильская, фәндә - Гыйлем Камай, Хәмит Мөштәри, Николай Чеботарев, Николай Четаев һ.б. исемнәре яңгырый.




1940. Бер төркем язучылар Васильевода





1939 елның 17 июнендә “Качкын” операсы куелышы белән Татар опера һәм балет театры ачыла

# Дәһшәтле сугыш елларында

Хәрәкәттәге армиягә республикадан 700 меңләп кеше алына. Шулардан 350 меңгә якыны (һәр икенчесе) Ватаныбыз азатлыгын һәм бәйсезлеген яклап сугышканда һәлак була. Аларның исемнәре 27 томлы Хәтер китабына кертелгән. Бөек Ватан сугышында катнашучы Советлар Союзы Геройлары арасында татарлар саны 179 кеше тәшкил итә.





Республика заманча хәрби техника җитештерүче иң эре үзәкләрнең берсенә әйләнә. Республика предприятиеләрендә смолетлар , снарядлар, патроннар, бомбалар, пехота һәм танкларга каршы миналар, авиация һәм танк приборлары, парашютлар, десант көймәләре, оптик приборлар, элемтә чаралары, сугыш өс һәм аяк киемнәре, азык-төлек һәм фронт өчен башка кирәк-яраклар җитештереп чыгарыла.

У-2 387 нче заводның җыю цехында . Казан, 1943

# Сугыштан соң



1970 ел. Түбән Каманың СКИ заводында беренче брикет каучукны җитештерү



1940 нчы еллар ахырында Ромашкино, Баулы, Зәй нефть чыганаклары ачыла һәм үзләштерелә. Шул чордан башлап, республикада нефть чыгару күләме туктаусыз үсә. 1961 елда Түбән Кама нефть химиясе комбинатына нигез салына. 1969 елда Кама автомобиль заводы – гаять зур автогигант төзелеше башлана. 1976 елның февралендә конвейердан беренче авыр йөк автомобиле – “КАМАЗ” төшә. 1960-1970 нче елларда Зәй ГРЭСы, Түбән Кама ГРЭСы эшли башлый.

# КАМАЗ – ул шәһәр, шәһәр ул – КАМАЗ

Татарстанны, Чаллыны КАМАЗдан башка күз алдына да китереп булмый. Ул Кама буенда урнашкан ак калабызның символына әйләнде. Чит илләрдә дә Татарстанны автогигант аша беләләр. Ул 1969 елда йөк машиналары җитештерүче заводлар комплексы буларак барлыкка килде. Сергей Когогин җитәкчелегендәге коллектив икътисадый кыенлыкларны җиңеп, йөк машиналарының төрле модельләрен җитештерүен дәвам итә.



КамАЗ-55111 моделе — берничә дистә ел дәвамында иң популяр автомобильләрнең берсе, бигрәк тә үзбушаткычлар составында



КамАЗ-63968 "Тайфун-К" — "КамАЗ"ның бронялы универсаль хәрби машиналары төркемендәге өр-яңа үрнәкләрнең берсе.

# Татарстан Республикасы — суверен дәүләт

1990 елда Дәүләт суверенитеты турындагы декларацияне игълан итү 1920 елда ТАССР төзелү турындагы Декретта билгеләнгән дәүләтчелекне торгызу процессының табигый дәвамы була. 1990 нчы еллардагы үзгәртеп корулар, социаль-икътисадый реформалар нәтиҗәсендә республика сәясәттә, икътисадта һәм мәдәнияттә, халыкара багланышларда мөстәкыйльлек ала, аның тарихи үсешенең үз мантыйгы пәйда була.



Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында декларация. 1990 ел

Минтимер Шәрип улы Шәймиев – Татарстан Республикасының беренче президенты . 1996 елда Президент вазифасына керешү тантанасы



Рөстәм Миңнеханов: “Татарстанның бүгенге казанышларының үткәндә салынган ныклы нигезе бар.Бередә милләтара, конфиссияара дуслык, аңлашу төрле төбәкләр һәм илләр өчен үрнәк. Татарстанлылар бүген икътисадтагы казанышлар, мәдәнияттагы уңышлар, спорттагы җиңүләр белән горурлана ала».




Рөстәм Миннехановның Татарстан Республикасы Президенты вазифасына керешүе

В.В. Путин, М.Ш. Шәймиев һәм Р.Н. Миннеханов




# Казан - Татарстан Республикасының башкаласы.

Хәзерге Казан, үзенең тарихи-мәдәни кыйммәте һәм сакланып калган мирасы буенча Россиянең өченче башкаласы дип санала. Сөембикә манарасы, Благовещенск соборы, Пушечный двор биналар комплексы, Колшәриф мәчете дөньякүләм мирас булып саналалар һәм бөтендөнья хәзинәсе статусына ия. Казан Кремле үзенең башлангыч дәвереннән төп үзенчәлекләрен саклап калган һәм дөньяда бердәнбер дәүләт хакимияте үзәгендәге татар ныгытмасы буларак, ЮНЕСКО объектлары исемлегенә кертелгән.



Кол Шәриф мәчете

Татарстан дөньякүләм масштабтагы зур чаралар үткәрү урынына әверелде. Бөтендөнья җәйге XXVII Универсиада 2013 елның 6 июленнән 17 июленә кадәр Казан шәһәрендә үткәрелде һәм ул иң масштаблысы булды.





# ТАТАРСТАН

Татар иле Татарстан,
Син яңадан калыктың.
Син - рухы, көче, намусы
Татар дигән халыкның.
Яшелле, аклы, кызыллы
Әлемең җилфердәсен,-
Әй, Казан ханлыгы улы,
Тарихлы да, яшь тә син!
Олпат та син, горур да син,
Ниятең пакьдин пакьтер –
Син шатлыктан елый белгән
Баһадир кебек матур!
Татар иле Татарстан,
Син яңадан калыктың;
Син - рухы, көче, намусы
Татар дигән халыкның!

Ренат Харис

